РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ МИЧАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422055, Республика Татарстан, Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная, 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЧЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422055, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Мичэн авылы, Мэктэп урамы, 12 йорт

тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.09.2018 г. № 20

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында” 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Мичән авыл җирлеге Советының 07.09.2017 № 19 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Мичән авыл җирлеге башкарма комитетының 07.09.2018 № 21 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Керәнне авылы Молодёжная, Залесная урамнарының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Мичән авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Гәрәев